# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

“29” март 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 29 мартында 10 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:

Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Яңа Шимбер торак пунктында гражданнар Җыенының 23.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү:

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Яңа Шимбер авылы зиратын төзекләндерү (үлән чабу, агачлар һәм куаклар кисү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү))

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 40 (кырык) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 22 (егерме ике) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 22 (егерме ике) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Яңа Шимбер торак пунктында гражданнар Җыенының 23.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү” :

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Яңа Шимбер авылы зиратын төзекләндерү (үлән чабу, агачлар һәм куаклар кисү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү)) мәсьәләсе буенча карарны танырга.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.